Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлеге составына керүче Олы Аты торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

КАРАР

2023 елның 11 ноябре № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 11 ноябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Кызыл Чапчак авыл җирлеге Олы Аты торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның ире/хатынынннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 2024 елда 3000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү белән килешәсезме:

– Кооперативная урамын зиратка кадәр юлны ремонтлау;

– Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлегенең Олы Аты торак пунктында 21.10.2020 елның 5 номерлы гражданнар җыены карары нигезендә, балалар мәйданчыгын төзекләндерүгә җыелган гражданнарның үзара салым акчаларын Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булган сугышчылар һәйкәлен төзекләндерүгә 49550 (кырык тугыз мең биш йөз илле) сум җибәрергә.

“ӘЙЕ” “ЮК””

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 195 җыенда катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны 106 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде: «Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 106 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлеге составына керүче Олы Аты торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбән Кама муниципаль районының Кызыл Чапчак авыл җирлеге Олы Аты торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның ире/хатынынннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 2024 елда 3000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү белән килешәсезме:

– Кооперативная урамын зиратка кадәр юлны ремонтлау;

– Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлегенең Олы Аты торак пунктында 21.10.2020 елның 5 номерлы гражданнар җыены карары нигезендә, балалар мәйданчыгын төзекләндерүгә җыелган гражданнарның үзара салым акчаларын Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булган сугышчылар һәйкәлен төзекләндерүгә 49550 (кырык тугыз мең биш йөз илле) сум җибәрергә.

“ӘЙЕ” “ЮК””

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына һәм Кызыл Чапчак авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кызыл Чапчак авыл җирлеге башлыгы Б.В.Ильдарханов